ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2025 елның «24» ноябреннән № 250

**«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының казна һәм бюджет учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» муниципаль казна учреждениесе җитәкчесенең һәм белгечләренең хезмәте өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында» Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 07 июлендәге 156 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының казна һәм бюджет учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» муниципаль казна учреждениесе җитәкчеләренә һәм белгечләренә социаль гарантияләрне тәэмин итү, хезмәт өчен түләүне тәртипкә салу һәм камилләштерү максатларында Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы казна һәм бюджет учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» муниципаль казна учреждениесе җитәкчесенең һәм белгечләренең хезмәтенә түләүне оештыру һәм түләү шартлары турында» 2023 елның 7 июлендәге 156 номерлы карары белән (2024 елның 06 маендагы 138 номерлы, 2024 елның 26 сентябрендәге 244 номерлы, 2024 елның 30 октябрендәге 269 номерлы, 2025 елның 08 апрелендәге 92 номерлы үзгәрешләр белән) расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы казна һәм бюджет учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» муниципаль казна учреждениесе җитәкчесенең һәм белгечләренең хезмәтенә түләүне оештыру һәм түләү шартлары турында нигезләмәнең 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының казна һәм бюджет учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» муниципаль казна

учреждениесе җитәкчесенең һәм белгечләренең вазыйфаи окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Җитәкче һәм белгечләрнең вазыйфалары | Вазыйфаи оклад, сум Муниципаль учреждение булып торучы үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен |
|---|---|
| Муниципаль учреждение җитәкчесе | 40 700 |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе урынбасары | 38 100 |
| Бүлек башлыгы | 33 600 |
| Әйдәүче бухгалтер | 30 600 |
| Бухгалтер | 29 000 |

Муниципаль учреждение булып торучы үзәкләштерелгән бухгалтериянең штат расписаниесенә җитәкче урынбасары вазыйфасын кертү шарты булып структурада кимендә 5 берәмлек штатлы 3 бүлек булу тора.

Үзәкләштерелгән бухгалтерия бүлекләренең штат саны кимендә 5 берәмлек булырга тиеш.».

2. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында https:/novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов